КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 29 май г.Казань № б-1174

Спортның техник спорт төрләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру һәм халыкны актив ял итүгә җәлеп итү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 5 июленнән 7 июленә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә 2023 елгы «Ефәк юл» халыкара раллие (алга таба – Ралли) этабын үткәрү, 2023 елның 6 июлендә Казан шәһәрендә Раллиның старт тантанасын оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу боерыкка теркәлгән 2023 елның 5 июленнән 7 июленә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә 2023 елгы «Ефәк юл» халыкара раллие этабын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Раллида катнашучылар урнашкан урыннарда шартнамә нигезендә медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Раллины әзерләү һәм үткәрү барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең, Татарстан Республикасы Лаеш, Мамадыш, Питрәч һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарының башкарма комитетларына муниципаль берәмлекләрнең тиешле территорияләрендә Раллины үткәрүдә ярдәм күрсәтүне;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Ралли үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә Раллида катнашучылар яшәгән һәм тукланган урыннарда санитария-

эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында тиешле чаралар үткәрүне тәэмин итүне;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә Ралли үткәрелә торган урыннарда янгын куркынычсызлыгы чаралары үтәлешенә күзәтчелек итүне тәэмин итүне.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 май, б-1174 нче
боерыгы белән расланды

2023 елның 5 июленнән 7 июленә кадәр
Татарстан Республикасы территориясендә 2023 елгы
«Ефәк юл» халыкара раллие этабын әзерләү һәм үткәрү буенча
республика оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Чагин Владимир Геннадьевич | «Ефәк юл» халыкара раллие» проекты җитәкчесе, «КАМАЗ-автоспорт» коммерциягә карамаган партнерлыгы директоры, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абусев Азат Габдулла улы | «Ефәк юл» халыкара раллие» проекты җитәкчесе урынбасары – урнаштыру буенча директоры (килешү буенча) |
| Авдонина Любовь Геннадьевна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Гарипов Рөстәм Рамил улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гомәров Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Егоров Иван Михайлович | «Татарстан Республикасы Автомобиль спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча) |
| Зарипов Илдус Фатыйх улы | Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Зарипов Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| Иванов Анатолий Петрович | Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Исләмов Радик Рамис улы | Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Кашапов Илһам Миңнехан улы | Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Миннәхмәтов Радик Җәүдәт улы | «Казан Арена» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнуллин Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Прытков Евгений Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Иҗтимагый тәртип саклауны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеген оештыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Садриев Илдар Зөфәр улы | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры – Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры. |